ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2019 г. Заинск № 486

**«Зәй шәһәреннән 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан һәм аз санда халык яши торган авыл торак пунктларына көн дә кирәкле куллану товарлары илтү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының өлешчә чыгымнарын каплауны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләү Тәртибен раслау турында" Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 2252нче (08.12.2017) карарына үзгәрешләр кертү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131нче федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставын кулланып, муниципаль район Башкарма комитеты

## карар бирә:

Башкарма комитетның 2252нче карары (2017 ел, 8 декабрь) белән расланган кулланучылар кооперациясе оешмаларының шәһәрдән еракта урнашкан һәм аз санда халык яши торган авылларына көндәлек товарлар илтү чыгымнарын район бюджетыннан субсидияләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 2.2 пунктында "һәм Зәй муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.2 2.3 пунктында:

а) 2нче абзацны төшереп калдырырга;

б) 9нчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"субсидия алучылар әлеге документның 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларда хокукый актлар, башка норматив актлар яки муниципаль актлар нигезендә субсидия

бирү планлаштырылган Россия Федерациясе бюджет системалары бюджетыннан субсидия алмаска тиеш”.

1.3 2.9 пунктны төшереп калдырырга.

2. Карар рәсми төстә басылган көннән үз көченә керә.

3. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И.Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**